| МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.12.2021 Казан ш. № 11-132

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәне раслау хакында” 11.08.2016 ел, № 11-96 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәне раслау хакында” 11.08.2016 ел, № 11-96 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә (14.06.2019 ел, № 11-66 боерыгы белән расланган үзгәрешләр белән) кертелә торган үзгәрешләрне (кушымта итеп бирелә) расларга.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
20.12.2021 № 11-132
боерыгы белән расланды

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәне раслау хакында” 11.08.2016 ел, № 11-96 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә кертелә торган үзгәрешләр

1. 2.1 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Министрлык эшчәнлегенә иҗтимагый контрольлекне хәл итү».

2. 2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Иҗтимагый совет бурычлары булып тора:

финанс, бюджет, салым өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерүдә катнашу;

Министрлык тарафыннан карарлар кабул итүдә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу механизмын камилләштерү;

Министрлыкның төп эшчәнлеге юнәлешләре буенча җәмәгатьчелекнең мәгълүматлылыгын үстерү;

җәмгыятьтә коррупциягә карата нәфрәт булдыру.».

3. 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 2.4 пунктын өстәргә:

«2.4. Иҗтимагый совет әлеге максатларга һәм куелган бурычларны хәл кылуга ирешү өчен:

финанс, бюджет, салым өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли;

коррупциягә каршы көрәшү буенча эшчәнлектә катнаша;

“Россия Федерациясендә җәмәгатьчелек контрольлеге нигезләре турында” 21 июль, 2014 ел, № 212-ФЗ Федераль закон нигезендә, Министрлык тарафыннан эшләнелеп, Иҗтимагый совет утырышында башлангыч фикер алышуларсыз гына кабул ителә алмый торган норматив-хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза үткәрүне оештыра;

Министрлык тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең сыйфатына мониторингта катнаша;

Министрлыкның дәүләт сатып алуларының нәтиҗәлелеген бәяләүдә катнаша;

дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләти гражданлык хезмәткәрләрен аттестацияләү өчен аттестация комиссияләре һәм дәүләти

гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү буенча конкурс комиссияләре эшендә катнаша.».

4. 3.6 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

«бу Нигезләмәнең пунктом 6.6 пунктында күздә тотылган нигезләмәләрнең булуы.».

5. 3.7 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

«Иҗтимагый совет әгъзасында мәнфәгатьләр бәрелешенә китерә торган яки китерә алырдай шәхсән кызыксынуның барлыкка килүе.».

6. 3.8 пунктта:

беренче абзацында “яки рәис урынбасары” сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацында “яки рәис урынбасарына” сүзләрен төшереп калдырырга;

7. Түбәндәге эчтәлектәге 6 бүлекне өстәргә:

«6. Иҗтимагый советта мәнфәгатьләр бәрелеше

6.1. Мәнфәгатьләр бәрелеше – Иҗтимагый совет әгъзасының шәхсән кызыксынуының үз бурычларын (вәкаләтләрен) тиешенчә, гадел төстә һәм намуслы хәл кылуга йогынты ясый торган яки йогынты ясый алырдай хәлләрнең килеп чыгуы һәм шул ук вакытта Иҗтимагый совет әгъзасының шәхсән кызыксынуы белән Иҗтимагый совет максатлары, бурычлары арасында каршылыкларның килеп чыгуы яки килеп чыга алуы.

6.2. Иҗтимагый совет әгъзасының үз бурычларын (вәкаләтләрен) тиешенчә, гадел төстә һәм намуслы хәл кылуга йогынты ясый торган яки йогынты ясый алырдай шәхсән кызыксынуы Иҗтимагый совет әгъзасы тарафыннан яки, кыйммәтләр, башка мөлкәт, шул исәптән мөлкәти хокуклар, яисә үзе өчен яки өченче затлар өчен хезмәтләр рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеген аңлата.

6.3. Иҗтимагый совет әгъзасы Иҗтимагый совет рәисенә һәм министрга, язмача рәвештә, үзенә мәгълүм булуга ук, килеп чыккан мәнфәгатьләр бәрелеше турында яки аның килеп чыгу ихтималы турында хәбәр итәргә, ә Иҗтимагый совет рәисе – бу хакта Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына язмача рәвештә хәбәр итәргә тиеш

Иҗтимагый совет рәисе, үзенә мәгълүм булуга ук, килеп чыккан мәнфәгатьләр бәрелеше турында яки аның килеп чыгу ихтималы турында министрга һәм Татарстан республикасы Иҗтимагый палатасына язмача рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

6.4. Иҗтимагый совет әгъзасында мәнфәгатьләр бәрелеше китерә торган яки мәнфәгатьләр бәрелешенә китерә алырдай шәхсән кызыксынуның барлыкка килүе турында үзенә мәгълүм булган Иҗтимагый совет рәисе яки Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, шул исәптән, министрга мәнфәгатьләр бәрелеше ягы булып

торган Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләрен туктатып тору яки туктату турында, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, тәкъдимнәр кертү юлы белән, мәнфәгатьләр бәрелешен кисәтү яки җайга салу буенча чаралар күрүгә бурычлы.

6.5. Иҗтимагый совет рәисе яки Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Иҗтимагый совет эшчәнлегенең коррупцион куркынычлар ихтималын бәяли һәм, Иҗтимагый совет әгъзаларының коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законын бозу билгеләреннән торучы эшчәнлектә катнашуларына юл куймау максатыннан, аларны ничек тә киметү чараларын күрә.

Иҗтимагый совет рәисе, үзенә Иҗтимагый совет әгъзасының коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законын бозу билгеләреннән торучы эшчәнлектә катнашуы турында мәгълүм булгач, өч эш көне эчендә бу хакта министрга һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына язмача рәвештә хәбәр итә.

Иҗтимагый совет әгъзалары, үзләренә Иҗтимагый совет рәисенең коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законын бозу билгеләреннән торучы эшчәнлектә катнашуы турында мәгълүм булгач, өч эш көне эчендә бу хакта министрга һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына язмача рәвештә хәбәр итә.

6.6. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, Иҗтимагый совет әгъзасының коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законын бозу билгеләреннән торучы эшчәнлектә катнашуы турында мәгълүмат алыну очракларында, Иҗтимагый совет әгъзасының Иҗтимагый совет эшендә катнашуын туктатып тору турында министрга тәкъдим кертә.

Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләрен туктатып тору турында министр карары, Министрлыкның боерыгы нигезендә, бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тәкъдим алынганнан соң утыз көн эчендә, расланылырга тиеш.

6.7. Иҗтимагый совет әгъзасында мәнфәгатьләр бәрелешен китереп чыгаручы хәлләр юкка чыгарылмаганда яки Иҗтимагый совет рәисенең коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законын бозу билгеләреннән торучы эшчәнлектә катнашуы расланганда, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы министрга Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату турында тәкъдим кертә.

Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату турында министр карары, Министрлыкның боерыгы нигезендә, бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тәкъдим алынганнан соң утыз көн эчендә, расланылырга тиеш.

6.8. Иҗтимагый совет әгъзасында мәнфәгатьләр бәрелешен китереп чыгаручы хәлләр юкка чыгарылганда (расланмаганда) һәм (яки) Иҗтимагый совет әгъзасының

коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законын бозу билгеләреннән торучы эшчәнлектә катнашуы расланмаганда, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы министрга Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләрен яңарту турында тәкъдим кертә.

Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләрен яңарту турында министр карары, Министрлыкның боерыгы нигезендә, бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тәкъдим алынганнан соң утыз көн эчендә, расланылырга тиеш.».